РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» сентября 2021г. г. Альметьевск № 46

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2015 елның 16 июнендәге 184 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 08 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2015 елның 16 июнендәге 184 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2019 елның 26 июлендәге 158 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Исемлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре милкендә булган муниципаль мөлкәне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга, шулай ук индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга тапшыру өчен исемлекне булдыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында;

1.2. Преамбулада һәм 1 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, шулай ук индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

1.3. 1 нче кушымтаның «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегенең исемендә һәм 1.1 пунктында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, шулай ук индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

1.4. 1 нче кушымтаның «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегенең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2 Исемлекне формалаштыру муниципаль милек белән идарә итү буенча вәкаләтле орган-Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы"нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советеның икътисадый үсеш һәм эшкуарлык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Великий С.И.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов